СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 1-2 от « 14 » ноября 2025 г.

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы бюджеты проекты турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 79 статьясына һәм Мамадыш муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмәгә таянып,Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы бюджеты проектын беренче укылышта кабул итәргә. (1 нче кушымта)

2. 2026 елга, 2027 һәм 2028 елларның планлы чорына Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының бюджет проектын (1 нче кушымта), 2026 елга, 2027 һәм 2028 елларның планлы чорына Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының бюджет проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу, шулай ук гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибен (2 нче кушымта) Мамамдыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. 2026 елга, 2027 һәм 2028 елларның планлы чорына Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының бюджет проекты турында ачык тыңлауларны 2025 елның 09 декабренә 09.00 сәгатьтә Мамадыш шәһәре, Давыдов урамы, 153 В йорт (РайПо бинасының актлар залы) адресы буенча үткәрелә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының бюджет, икътисадый сәясәт, сәнәгать, эшкуарлык, аграр сәясәт, җирдән файдалану һәм экология буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Мамадыш
муниципаль районы
Башлыгы В.И.Никитин

000109